# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАР

«01» 12 2020 ел Яр Чаллы № 4634

«2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы территориясендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча ярдәмче программа»ны раслау турында

«Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, «Террорчылыкка каршы тору чаралары турында» 2006 елның 15 февралендәге 116 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, Россия Федерациясе Президентының 2018 елның 28 декабрендәге Пр-2665 номерлы боерыгы белән расланган 2019-2023 елларга Россия Федерациясендә террорчылык идеологиясенә каршы тору комплекслы планына таянып, һәм «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылыкка һәм экстремизмга каршы көрәш буенча профилактик эшчәнлекне көчәйтү, шулай ук район территориясендә террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яисә) юкка чыгару, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Тукай муниципаль районы Уставы нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. 2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау муниципаль ярдәмче программасын 1 кушымта нигезендә расларга.
2. «2018-2020 елларга Тукай муниципаль районы территориясендә экстремизмны һәм террорчылыкны профилактикалау буенча ярдәмче программаны раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 28 февралендәге 606 номерлы карары 2021 елның 1 январеннан үз көчен югалта дип танырга.
3. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты бүлекләре һәм җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә ярдәмче программа чараларын башкару буенча оештыру-гамәли чараларны тормышка ашыруны тәэмин итәргә.
4. Тукай муниципаль районының финанс-бюджет палатасына бюджет

формалаштырганда, ярдәмче программаны гамәлгә ашыру срокларын исәпкә алып, ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыруга район бюджеты акчалары хисабына финанс чаралары бүлеп бирүне күздә тотарга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 01. 12 1633 номерлы карарына кушымта

**«2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау» муниципаль ярдәмче программасы**

## 1. Муниципаль ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| 1. Ярдәмче программаның исеме | «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау» муниципаль ярдәмче программасы |
| 2. Ярдәмче программаны эшләү нигезе | «Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, «Террорчылыкка каршы тору чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2006 елның 15 февралендәге 116 номерлы Указы, «Экстремизм эшчәнлегенә каршы тору турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2018 елның 28 декабрендәге Пр-2665 номерлы боерыгы белән раслаган «2019-2023 елларга Россия Федерациясендә террорчылык идеологиясенә каршы тору комплекслы планы» |
| 3. Ярдәмче программа координаторы | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 4. Ярдәмче программаны эшләүче | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссия (алга таба – Комиссия) |
| 5. Ярдәмче программаның төп максатлары | Тукай муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен юнәлешләре буенча тормышка ашыру:<br>- Тукай муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарның тормышын һәм тынычлыгын, аларның экстремизмга һәм террорчылыкка каршы тору нигезендә законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау дәрәҗәсен күтәрү, экстремизм һәм террорчылык күренешләрен профилактикалау һәм кисәтү;<br>- этникара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны саклау;<br>- гомумроссия гражданлык тәңгәллеген ныгыту;<br>- мигрантларны уңышлы социомәдәни җайлаштыру һәм |

| | |
|---|---|
| | интеграцияләү;<br>- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнар тормышын террорчылык һәм экстремизм актларыннан саклау максатында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау |
| 6. Ярдәмче программаның төп бурычлары | - Башка милләт һәм дини конфессияләр вәкилләренә карата экстремизм күренешләрен һәм тискәре мөнәсәбәтне киметү;<br>- күпмилләтле Россия җәмгыяте, мәдәни үзаң, кеше хокукларын һәм иреген саклау принциплары нигезендә башка милләт, дини конфессия кешеләренә карата толерант караш пропагандалау һәм формалаштыру;<br>- яшьләр арасында толерантлык һәм этникара культура формалаштыру, агрессив тәртипне профилактикалау;<br>- террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору мәсьәләләре буенча Тукай муниципаль районы халкына үз вакытында һәм объектив мәгълүмат бирү<br>- балалар һәм яшьләр арасында экстремистик характердагы гамәлләр кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерүгә юнәлдерелгән тәрбия эшен оештыру |
| 7. Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2021-2023 еллар |
| 8. Ярдәмче программаны башкаручылар | Комиссия әгъзалары, «Мәгариф идарәсе» МКУ, район яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, район мәдәният идарәсе бүлеге, дини һәм иҗтимагый оешмалар |
| 9. Ярдәмче программаны финанслау чыганаклары | 2021-2023 елларга ярдәмче программаны үз эченә алган «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында милли сәясәтне гамәлгә ашыру» программасын финанслауның гомуми күләме 513 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2021 елда -165 мең сум;<br>2022 елда - 171 мең сум;<br>2023 елда - 177 мең сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.<br>Республика, федераль бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклардан средсволар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк |

| | |
|---|---|
| | Әлеге ярдәмче программаны тормышка ашыру белән бәйле чараларны финанслау тиешле финанс елына Тукай муниципаль районы бюджетында расланган ассигнованиеләр чикләрендә гамәлгә ашырыла. Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруга тотылган средстволар күләме район бюджеты мөмкинлекләреннән, инфляция процессларыннан һәм Тукай муниципаль районы территориясендәге икътисадый хәлдән чыгып аныкланырга һәм төзәтмәләр кертелергә мөмкин |
| 10. Ярдәмче программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре | Ярдәмче программаны тормышка ашыруның йомгаклау нәтиҗәләре:<br>- Тукай муниципаль районы территориясендә террорчылыкны һәм экстремизмны, ксенофобияне, милли һәм раса түземсезлеген профилактикалау, этник дискриминациягә каршы тору буенча җирле үзидарә органнарының эш формаларын һәм ысулларын камилләштерү;<br>- укучылар арасында интернационализм, татулык, милли һәм дини түземлелек культурасын үстерү;<br>- террорчылык һәм экстремизм күренешләренең барлык фактларына түземсезлек формалаштыру;<br>- башка этник һәм дини берләшмәләр вәкилләренә толерант караш формалаштыру;<br>- яшьләр даирәсендә этникара татулык һәм толерантлык атмосферасын ныгыту һәм үстерү;<br>- Тукай муниципаль районы территориясендә толерантлык, гражданлык теләктәшлеге, башка культураларга карата хөрмәт идеяләрен пропагандалау һәм тарату өчен, шул исәптән муниципаль массакүләм мәгълүмат чаралары аша, бердәм мәгълүмати киңлек булдыру |
| 11. Ярдәмче программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы | Комиссия квартал саен һәм һәр ел нәтиҗәләре буенча ярдәмче программаны гамәлгә ашыруны контрольдә тота. Социаль-икътисадый ситуацияне исәпкә алып, ярдәмче программа чараларын төгәлләштерү буенча билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертә |

## ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММА ХӘЛ ИТҮГӘ ЮНӘЛДЕРЕЛГӘН ПРОБЛЕМАНЫҢ ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ

Ярдәмче программа иҗтимагый-сәяси көчләрне, милли-мәдәни, мәдәни һәм дини оешмаларны берләштерү һәм гражданнар иминлеге буенча максатчан, эзлекле эш принципларын гамәлгә ашыруның мөһим юнәлеше булып тора. Төбәкнең генә түгел, тулаем илнең дә куркынычсызлыгына турыдан-туры куркыныч тудыра торган җәмгыятьтәге социаль киеренкелек, дәвам итүче этникара һәм конфессияара конфликтлар, сепаратизм һәм милли экстремизм үсү шартларында толерант аң һәм тәртип, диннәргә тигез караш һәм тынычлыкка омтылу юнәлешен формалаштыру, экстремизмның төрле төрләрен профилактикалау хәзерге көндә аеруча актуаль. Бу күренешләр соңгы формаларында террорчылыкта чагылыш таба, ул, үз чиратында, җәмгыятьтә деструктив процессларны көчәйтә.

«2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау» муниципаль ярдәмче программасын эшләү һәм кабул итү шулай ук террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору өлкәсендә җирле үзидарә органнарының көчләрен алга таба берләштерү, аларның эшчәнлеген координацияләү дәрәҗәсен күтәрү һәм террорчылыкка һәм экстремизмга каршы нәтиҗәле чаралар әзерләү һәм гамәлгә ашыру, террорчылык янауларына каршы көчләрнең һәм чараларның әзерлеген тәэмин итү, террорчылык күренешләренең нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм бетерү, террорчылык һәм экстремизмны профилактикалауга комплексы якын килүне гамәлгә ашыру, террорчылык һәм экстремизм күренешләре барлыкка килүгә китерә торган шартларның һәм факторларның тискәре йогынтысын ачыклау һәм киметү зарурлыгына бәйле.

Тукай муниципаль районында милләтара мөнәсәбәтләрнең торышы тотрыклы, төрле этник төркемнәр һәм конфессияләр вәкилләренең үзара тыныч бәйләнеше һәм хезмәттәшлеге белән характерлана. Районда үзара хөрмәткә һәм ышанычка нигезләнгән милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр прогрессив тенденцияләр рәвешендә ныгытылды һәм иҗтимагый этномәдәни берләшмәләр һәм гражданлык җәмгыятенең башка институтлары белән хезмәттәшлектә муниципаль хакимият органнарының аерым кайгыртучанлыгы предметы булып тора.

Тукай муниципаль районы 23 авыл җирлеген берләштерә, алар территориясендә 88 торак пункт бар, 42511 кеше яши. Милли состав: татарлар – 71%, руслар – 24,2%, башка милләт вәкилләре – 4,8%. Районда милләтара мөнәсәбәтләр тотрыклы.

2020 елның 1 маена районда 64 дини оешма эшли:

- шуларның 59ы Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте юрисдикциясендә, 2 оешма төзелеш стадиясендә;

- Казан епархиясе карамагында 7 православие чиркәве, 3 төзелеп килүче православие чиркәве, 3 гыйбадәт йорты, 1 гыйбадәт бүлмәсе бар.

Нәкъ менә шуңа күрә әлеге өлкәдә дәүләт сәясәтенең төп бурычларыннан берсе - Татарстан Республикасында һәм муниципаль районда террорчылык янауларын кисәтү һәм булдырмау буенча заманча эш системасы булдыру.

Тәҗрибә күрсәткәнчә, террорчылык һәм экстремизм янауларыннан муниципаль район халкы һәм территориясе иминлеген тәэмин итү буенча эшләр, террорчылыкка каршы юнәлештәге өйрәнүләр һәм тренировкалар үткәрү, вазыйфаи затларның һәм белгечләрнең квалификациясе, шулай ук террорчылыкны һәм экстремизмны кисәтү буенча халыкның эш-гамәлләре нәтиҗәлелеге җитәрлек дәрәҗәдә түгел.

Хәзерге вакытта террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау мәсьәләләрендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтенең максаты булып террорчылык актларын һәм экстремистлык күренешләрен кисәтү һәм булдырмауга юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру хисабына террорчылык янауларыннан халыкның һәм территориянең гарантияле куркынычсызлыгы дәрәҗәсенә ирешү тора.

Экстремизм идеологиясен тарату ресурс ярдәмен һәм террорчылык оешмалары сафларына яңа әгъзалар килүен тәэмин итә. Террорчылык янавын киметү бурычы экстремизм идеологиясе таралуга актив каршы тору белән турыдан-туры бәйле. Аның йогынтысының төп максаты булып, гражданнар тәңгәллеге һәм хокук аңы күзлегеннән караганда, иң йомшак һәм тотрыксыз мохит буларак яшүсмерләр һәм яшьләр тора.

Экстремизмга, террорчылыкка, хокук бозулар кылуга этәрүче сәбәпләрне һәм шартларны кисәтүгә, ачыклауга, юк итүгә юнәлдерелгән чараларга системалы якын килү районда социаль-икътисадый хәлне яхшыртуның иң мөһим шартларыннан берсе булып тора. Мондый алымны гамәлгә ашыру өчен, террорчылыкны, экстремизмны профилактикалау һәм җәмәгать тәртибен саклау буенча халыкның ирекле формированиеләре эшчәнлеге өчен шартлар тудыру буенча муниципаль ярдәмче программа кирәк, ул хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә җирле үзидарә һәм башка субъектларның потенциалын максималь файдалануны күздә тотачак.

Ярдәмче программа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү өчен ачык документ булып тора.

## 1. Ярдәмче программаның төп максаты һәм бурычлары

Пргramманың максаты булып Тукай муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарның тормышын һәм тынычлыгын, аларның экстремизмга һәм террорчылыкка каршы тору нигезендә законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау дәрәҗәсен күтәрү, экстремизм һәм террорчылык күренешләрен профилактикалау һәм кисәтү тора.

Ярдәмче программаның төп бурычлары булып тора:

1) Милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгыту, социаль, этник һәм конфессиональ нигездә конфликтларны профилактикалау һәм булдырмау;

2) Халыкның террорчылык һәм экстремизм идеологиясе күренешләренә түземсезлек атмосферасын булдыруга юнәлтелгән җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру;

3) Яшьләр даирәсендә толерантлык һәм этникара культура формалаштыру,

агрессив тәртипне профилактикалау;

4) Террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору мәсьәләләре буенча Тукай муниципаль районы халкына мәгълүмат бирү;

5) Хокук саклау органнарына әлеге категориядәге хокук бозуларны һәм җинаятьләрне ачыклауда, шулай ук аларның нәтиҗәләрен бетерүдә ярдәм итү;

6) Башка милләт һәм дини конфессия кешеләренә карата толерант мөнәсәбәт пропагандалау;

7) Балалар һәм яшьләр арасында экстремизм характерындагы гамәлләр кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерүгә юнәлдерелгән тәрбия эшен оештыру.

## 2. Программа чаралары

Ярдәмче программа түбәндәге принципларга таянып гамәлгә ашырыла:

1) Экстремизм һәм террорчылык күренешләренә каршы тору һәм профилактикалау өлкәсендә актив мәгълүмати сәясәт принцибы. Күп гасырлык мәдәни-тарихи мираска һәм Татарстан Республикасы күпконфессияле һәм күпмилләтле җәмгыятенең мәдәни интеграциясенең уңай тәҗрибәсенә таянып, «Мин - Россия гражданины» позитив гражданлык идеологиясен пропагандалау;

2) Социаль ярдәм принцибы – конструктив иҗтимагый инициативаларга таяну, ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыру өчен халыкның социаль актив өлешен җәлеп итү;

3) Экстремизм һәм террорчылык күренешләренә актив каршы тору һәм профилактика принцибы. Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру актив сәясәте янау чыганакларын үз вакытында, төгәл ачыклауга һәм аларга алдан каршылык күрсәтүгә юнәлтелгән;

4) Килештерелгән идарә принцибы – комплекслылык, ведомствоара координацияләү һәм ярдәмче программаның максат һәм бурычларына ирешү дәрәҗәсенә даими контроль;

5) Чынбарлык принцибы – «кире элемтә»дән файдалану, ярдәмче программаның максат һәм бурычларын гамәлгә ашыруга мониторинг ясау.

## 3. Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру чорына барлыгы 513 мең сум планлаштырылган, шул исәптән ярдәмче программаны гамәлгә ашыру еллары буенча:

2021 елда – 165 мең сум;

2012 елда – 171 мең сум;

2023 елда – 177 мең сум.

Әлеге ярдәмче программаны тормышка ашыру белән бәйле чараларны финанслау тиешле финанс елына Тукай муниципаль районы бюджетында расланган ассигнованиеләр чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруга тотылган средстволар күләме район

бюджеты мөмкинлекләреннән, инфляция процессларыннан һәм Тукай муниципаль районы территориясендәге икътисадый хәлдән чыгып анықланырга һәм төзәтмәләр кертелергә мөмкин.

## 4. Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмы

Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау эшчәнлеге Тукай муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссия тарафыннан координацияләнә. Террорчылыкка каршы комиссия тарафыннан кабул ителгән карарлар Тукай муниципаль районы предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары җитәкчеләре тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш. Террорчылыкка каршы комиссия эшендә катнашу өчен суд органнары һәм прокуратура органнары вәкилләре аларның ризалыгы белән чакырыла ала.

Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә террорчылыкка каршы комиссия вәкаләтләренә керә:

- террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауның торышына комплекслы анализ үткәрү һәм алга таба профилактика субъектларына тәкъдимнәр әзерләү;
- террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча эш планнарын эшләү, аларның үтәлешен контрольдә тоту;
- Татарстан Республикасында террорчылыкка каршы комиссиягә профилактика эшчәнлегенең торышы турында мәгълүмат бирү, аның нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр кертү;
- террорчылыкны һәм экстремизмны кисәтү, аларны кылуга этәрүче сәбәпләрне һәм шартларны бетерү мәсьәләләре буенча предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләрен тыңлауны оештыру;

эшчәнлекне координацияләү:

- террорчылыкны һәм экстремизмны кисәтү, аны камилләштерү чараларын эшләү буенча;
- террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә норматив хокукый актлар әзерләү буенча;
- халык, иҗтимагый оешмалар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара аралашуны ныгыту һәм тыгыз хезмәттәшлекне җайга салу буенча.

## 5. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү тиешле ел эчендә фактта ирешелгән күрсәткечләрне максатчан индикаторлар белән чагыштыру юлы белән башкарыла.

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:

- Тукай районы территориясендә террорчылык актлары кылу ихтималын киметү;
- террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау муниципаль

системасының нәтиҗәлелеген арттыру;

- террорчылыкны һәм экстремизмны кисәтү буенча эшчәнлекне оештыруга предприятиеләрне, учреждениеләрне, барлык милек формасындагы оешмаларны, шулай ук иҗтимагый оешмаларны җәлеп итү;

- террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауны норматив хокукый җайга салуны алга таба үстерү;

- Тукай муниципаль районы территориясендә куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча муниципаль органнар һәм иҗтимагый оешмалар эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итүне яхшырту;

- халыкның хокук саклау органнарына ышаныч дәрәҗәсен арттыру.